КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1059

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 2 август, 366 нчы; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 19 август, 599 нчы; 2015 ел, 13 апрель, 250 нче; 2015 ел, 12 сентябрь, 669 нчы; 2017 ел, 15 август, 578 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 740 нчы; 2020 ел, 28 гыйнвар, 40 нчы; 2020 ел, 31 гыйнвар, 51 нче; 2020 ел, 24 февраль, 131 нче; 2020 ел, 24 март, 217 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1234 нче; 2021 ел, 28 октябрь, 1009 нчы; 2022 ел, 1 март, 189 нчы, 2023 ел, 20 февраль, 167 нче; 2023 ел, 31 октябрь, 1374 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләренә һәм тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

19 пунктта «биш ел» сүзләрен «өч ел» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә 2 нче кушымтаның 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Гаилә составы ________ кеше:

| Т/с | Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) тулысынча* | Туганлык мөнәсәбәтләре** | Туу датасы | Туу урыны | Шәхес таныклыгы | | | | | Физик затның ИННы (салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры) | СНИЛС (индивидуаль шәхси счетның иминият номеры) | Эш, уку урыны | Эш стажы | Оешманың ИННы (салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | документ төре | сериясе | номеры | кем биргән | бирү датасы | | | | | |
| 1. | | | | | | | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | | | | | | | | |
| 4. | | | | | | | | | | | | | | »; |

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә 4 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 9.1 нче юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «9.1. | гариза бирүченең һәм гаиләнең һәр әгъзасының СНИЛСы (индивидуаль шәхси счетның иминият номеры)»; |

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә 5 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 9.1 графа өстәргә:

| «СНИЛС (индивидуаль шәхси счетның иминият номеры) |
|---|
| 9.1»; |

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә 6 нчы кушымтага түбәндәге эчтәлекле 2.9.1 пункт өстәргә:

«2.9.1. 9.1 бүлектә гаиләнең һәр әгъзасының СНИЛСы (индивидуаль шәхси счетның иминият номеры) күрсәтелә.»;

әлеге Кагыйдәләргә һәм тәртипкә 7 нче кушымтада:

1 бүлекнең өченче – җиденче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

2 бүлекнең җиденче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 ел, 2 август, 366 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 8 октябрь, 543 нче; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 14 май, 321 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2013 ел, 29 октябрь, 806 нчы; 2015 ел, 15 гыйнвар, 7 нче; 2015 ел, 13 апрель, 250 нче; 2016 ел, 19 август, 576 нчы; 2016 ел, 5 декабрь, 892 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 740 нчы; 2020 ел, 31 гыйнвар, 51 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1234 нче; 2022 ел, 17 июнь, 579 нчы; 2023 ел, 31 октябрь, 1374 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның беренче абзацында «торак урыннар» сүзләрен «фатирлар сайлап алу конкурсында катнашу хокукы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен гражданнарның түләүләр шартларын һәм срокларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 13 июль, 587 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 декабрь, 1234 нче; 2022 ел, 1 март, 189 нчы; 2023 ел, 20 февраль, 167 нче; 2023 ел, 4 апрель, 406 нчы; 2023 ел, 31 октябрь, 1374 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.4 пунктча өстәргә:

«3.4. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын алу нияте белән алар социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылырга мөмкин булган гамәлләр кылган, нәтиҗәдә алар социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәменә мохтаҗ дип танылырга мөмкин, социаль ипотека системасында торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алына, күрсәтелгән махсус гамәлләр башкарылган көннән соң өч елдан да иртәрәк түгел.»;

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Исәпкә алу делосының составы һәм аны алып бару тәртибе әлеге Тәртипкә 9 нчы кушымта нигезендә рәсмиләштерелә.»;

18 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәменә билгеләнгән тәртиптә хокук алган һәм социаль ипотека программасы шартларын үтәүче яшь гаиләләргә фатирлар сайлап алу конкурсында катнашу хокукы бирүнең иң чик срогы өч календарь ел тәшкил итә.»;

19 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Билгеләнгән квота кысаларында чират тәртибендә фатирлар сайлап алуга өстенлекле хокук өч календарь ел көтү срогы җиткән яшь гаиләләргә иң югары рейтинг буенча бирелә.»;

27 пунктта «28,5 елга кадәр» сүзләрен «15 елдан 28,5 елга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтаның 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Гаилә составы ________ кеше:

| Т/с | Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) тулысынча* | Туганлык мөнәсәбәтләре** | Туу датасы | Туу урыны | Шәхес таныклыгы | | | | | Физик затның ИННы (салым түләүченең тәнгәлләштерү номеры) | СНИЛС (индивидуаль шәхси счетның иминият номеры) | Эш, уку урыны | Эш стажы | Оешманың ИННы (салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | документ төре | сериясе | номеры | кем биргән | бирү датасы | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | | | | | | | | |
| 4. | | | | | | | | | | | | | | »; |

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 9.1 графа өстәргә:

| «СНИЛС индивидуаль шәхси счетның иминият номеры) |
|---|
| 9.1»; |

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 2.9.1 пункт өстәргә:

«2.9.1. 9.1 бүлектә гаиләнең һәр әгъзасының СНИЛСы (индивидуаль шәхси счетның иминият номеры) күрсәтелә.»;

әлеге Тәртипкә 9 нчы кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннар бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 7 март, 200 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 20 февраль, 167 нче; 2023 ел, 4 апрель, 406 нчы; 2023 ел, 31 октябрь, 1374 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

31 пунктта «28,5 елга кадәр» сүзләрен «15 елдан 28,5 елга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаның 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Гаилә составы ________ кеше:

| Т/с | Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) тулысынча* | Туганлык мөнәсәбәтләре** | Туу датасы | Туу урыны | Шәхес таныклыгы | | | | | Физик затның ИННы (салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры) | СНИЛС (индивидуаль шәхси счетның иминият номеры) | Эш, уку урыны | Эш стажы | Оешманың ИННы (салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | документ төре | сериясе | номеры | кем биргән | бирү датасы | | | | | |
| 1. | | | | | | | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | | | | | | | | |
| 4. | | | | | | | | | | | | | | »; |

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 9.1 графа өстәргә:

| «СНИЛС индивидуаль шәхси счетның иминият номеры) |
| --- |
| 9.1»; |

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 2.9.1 пункт өстәргә:

«2.9.1. 9.1 бүлектә гаиләнең һәр әгъзасының СНИЛСы (индивидуаль шәхси счетның иминият номеры) күрсәтелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен гражданнарның түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм срокларын билгеләү тәртибенә
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 25 ноябрь, 1059 нчы карары редакциясендә)

Түләүләрне кичектереп торуның дәвамлылыгын
билгеләү

| Башлангыч кертем күләме (торак урын бәясеннән процент) | Квоталар категориясе | Фатирларны сайлап алу рәвеше | Бер гражданга исәпләгәндә гаиләнең уртача айлык кереме | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | МКБ азрак[1] | МКБ алып 0,5 РКБ кадәр[2] | 0,5 РКБ алып РКБ дан артыграк |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Кимендә 1 000 сум | кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ гражданнар | квота чикләрендә әлеге категория буенча конкурс | 17 ел | 16 ел | 15 ел |
| 10 процент | бюджет өлкәсе хезмәткәрләре / социаль ипотеканы финанслауда катнашучы оешмалар хезмәткәрләре | оешмалар квотасы чикләрендә конкурс һәм бюджетчылар өчен 50 процент квота | 17 ел | 16 ел | 15 ел |
| 20 процент | бюджет өлкәсе хезмәткәрләре / социаль ипотеканы финанслауда катнашучы оешмалар хезмәткәрләре | оешмалар квотасы чикләрендә конкурс һәм бюджетчылар өчен 50 процент квота | 18 ел | 17 ел | 16 ел |

[1]МКБ – Минималь куллану бюджетының кыйммәти зурлыгы.
[2]РКБ – рациональ куллану бюджетының кыйммәти зурлыгы.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 30 – иң күбе 90 процент | бюджет өлкәсе хезмәткәрләре / социаль ипотеканы финанслауда катнашучы оешмалар хезмәткәрләре | оешмалар квотасы чикләрендә конкурс һәм бюджетчылар өчен 50 процент квота | 19 ел | 18 ел | 17 ел |

______________________________

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннар бирү тәртибенә
9 нчы кушымта

Исәпкә алу делосының составы һәм аны алып бару тәртибе

## I. Исәпкә алу делосын рәсмиләштерү

Исәпкә алу делосы җирле үзидарә органнарының торак хезмәтләре тарафыннан формалаштырыла.

Гариза бирүче тарафыннан гариза бирелеп, анкета тутырылып, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак ш\артларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннар бирү тәртибендә билгеләнгән формалар буенча документларның тулы пакеты бирелгәннән соң, җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле үзидарә органы боерыгы нигезендә яшь гаиләнең исәпкә алу делосын теркәү турындагы мәсьәлә карап тикшерелә.

## II. Исәпкә алу делосының составы

Исәпкә алу делосында түбәндәгеләр була:

исәпкә алу делосындагы документлар исемлеге;

гражданның Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннар бирү тәртибенә 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча социаль ипотека буенча торак урын сатып алу өчен исәпкә кабул итүне сорап язылган гаризасы;

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннар бирү тәртибенә 2 нче кушымта нигезендә гариза бирүчене һәм аның гаиләсен исәпкә алу турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен кирәкле документлар;

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннар бирү тәртибенә 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча гариза бирүченең анкетасы;

җирле үзидарә органының Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннар бирү тәртибенә 6 нчы кушымтада бирелгән форма буенча гариза бирүчене социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә кую турындагы боерыгы;

гариза бирүче белән аның торак мәсьәләсе буенча хат алышу материаллары, аларда керүче һәм чыгучы номерлары һәм алар буенча кабул ителгән карарлар күрсәтелә.

## III. Исәпкә алу делосын исәпкә алу, алып бару һәм саклау

Исәпкә алу делоларын исәпкә алу Гариза биргән гаиләләрне исәпкә алу кенәгәсендә кәгазь һәм электрон чыганакларда алып барыла.

Исәпкә алу делосында документлар керү даталары буенча хронологик тәртиптә, астан өскә таба урнашка, номерлана һәм кергән саен исемлеккә кертелеп бара.

Исәпкә алу делосына үзгәрешләр яшь гаиләне социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә куюны гамәлгә ашырган җирле үзидарә органының күрсәтмә һәм башка документлары нигезендә кертелә. Тиешле үзгәрешләр гаиләнең исәпкә алу карточкасына кертелә.

Исәпкә алу делосы җирле үзидарә органнарының гражданнарны исәпкә алу өчен җаваплы бүлекләрендә гариза бирүче махсуслаштырылган оешма белән төзелгән социаль ипотека шартнамәсе буенча сатып алынган торак урын бәясен тулысынча түләп бетергәнгә кадәр саклanyла. Гражданнарны исәпкә алу өчен җаваплы җирле үзидарә органнары гаиләләрне исәпкә алу кенәгәләрен, яшь гаиләләрнең исәпкә алу делоларын, электрон мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә саклауны тәэмин итә. Исәпкә алу делолары, торак урын сатып алынганнан соң, 10 ел дәвамында саклана.

## IV. Исәпкә алу делосын тапшыру

Исәпкә алу делосы түбәндәге очракларда тапшырыла:

контрольдә тоту, хокук саклау һәм башка вәкаләтле органнарга аларның соравы буенча;

яшәү урыны алыштырылганда гариза бирүченең яшәү урыны буенча җирле үзидарә органына.

---